КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 25 апрель г.Казань № 391

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген, аның территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектын һәм күчемсез мөлкәт объектларын алу турында

«Вознесенский тракты. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, $VII^1$ бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын (алга таба - Баштатюлтранс) тоту һәм үстерүнең төп идарәсе” дәүләт казна учреждениесенең «Вознесенский тракты. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Вознесенский п., Бахтизин ур., 13 йорт адресы буенча урнашкан, Л.М.Заһитова һәм Д.Р.Заһитовның өлешле милкендә булган (алга таба - алына торган мөлкәт милекчеләре) 1 200 кв.метр мәйданлы 16:50:270101:287 кадастр номерлы җир кишәрлеген, аның

территориясендәге 89,6 кв.метр мәйданлы 16:50:270101:867 кадастр номерлы капиталь төзелеш объектын һәм күчемсез мөлкәт объектларын (алга таба - алына торган мөлкәт) Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алу турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган мөлкәт милекчеләренә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган мөлкәт өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен мөлкәтне алу турында килешүләр (алга таба – килешүләр) әзерләүне һәм аларны алына торган мөлкәт милекчеләренә җибәрүне;

килешүләр төзүне;

алына торган мөлкәт өчен түләү;

алына торган мөлкәткә Татарстан Республикасы милек хокукын дәүләт теркәве;

алына торган мөлкәт милекчеләре тарафыннан имза куелган килешүләр законнар белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин